РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2025 № 406

**«2026 елга «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыруны финанслау бәясе нормативларын раслау турында»**

«Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләрендә баларны йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымтада бирелгән:

2026 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртүне оештыруны финанслау нормативларын;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне

расларга.

2.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына:

гомуми белем бирү учреждениеләрен әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Әтнә район башкарма комитеты
җитәкчесеӊ 2025 елныӊ
11 ноябрендәге 406 номерлы
карары белән расланган.

2026 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртүне оештыруны финанслау нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең исеме | Ике ставкалы нормативның күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга исәпләнгән сумма | автотранспорт чарасының бер километр йөрешенә ставка, бер елга исәпләнгән сумма |
| ПАЗ | 1 129 096,31 | 24,56 |
| ГАЗ «Газель» | 1 107 926,16 | 15,73 |
| Ford Transit | 1 116 227,96 | 16,08 |

Әтнә район башкарма комитеты
җитәкчесеӊ 2025 елның 11 ноябрендәге
406 номерлы карары белән расланган.

## Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - укучыларны йөртүне оештыру бәясе).
1.2. Укучыларны йөртүне оештыру бәясе, автотранспорт чаралары саны һәм отчет чорында автотранспорт чараларының чын йөреше нормативы нигезендә исәпләнә.
1.3. Укучыларны йөртүне оештыру нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты тарафыннан раслана.
1.4. Укучыларны йөртүне оештыру бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының чын йөгереше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының расланган маршрут паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының чынлыктагы йөреше буларак кабул ителә.

### 2. Укучыларны йөртүне оештыру бәясен исәпләү

2.1. Муниципаль берәмлекнең укучыларны йөртүне оештыру бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$

$S_i$ - укукчыларны йөртүне оештыру бәясе;
$n_{f\,m}$ - m моделле автотранспорт чараларының чынлыктагы йөреше, километрлар;
$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балаларны бер километрга йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;
$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән бер автотранспорт чарасына йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;
$M_m$ - m моделе автотранспорт чаралары саны, берәмлекләр;
$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;
$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.